Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородск авыл җирлеге Советының кырык җиденче утырыш

# КАРАРЫ

31 гыйнвар, 2025 ел. № 123

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородск авыл җирлеге башлыгы, муниципаль хезмәткәрләренең айлык акчалата бүләкләү күләмен арттыру турында

“Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, урынбасарларының, аудиторларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородск авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородск авыл җирлеге Советының 2021 елның 9 апрелендәге 23 номерлы карарына “Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородск авыл җирлеге башлыгы һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында” (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородск авыл җирлеге Советының 2022 елның 10 октябрендәге 54 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 64 номерлы, 2024 елның 29 маендагы 100 номерлы, 2024 елның 29 июлендәге 106 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләр белән) (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.1 подпунктта 1 пунктның “24 789” санын “26 029” санына алмаштырырга;

1.2. 1.2 подпунктта 1 пунктның “13 323” санын “13 990” санына алмаштырырга.

2. Әлеге Карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге Карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге Карар 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге
башлыгы урынбасары В. М. Барышев